ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.03.2020 Олы Кайбыч ав. 156

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы торак пунктларында төзекләндерү, чисталык һәм тәртип урнаштыру буенча икеайлык үткәрү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 24 февралендәге 388-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының торак пунктларын санитар чистартуны тәэмин итү, аларны халыкның экологик һәм санитар-эпидемиологик иминлегенә җавап бирә торган хәлгә китерү өчен, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Районда 2020 елның 1 апреленнән 31 майга кадәр Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының торак пунктлары территорияләрен чистарту буенча санитар-экологик икеайлык игълан итәргә (алга таба - икеайлык).

2. Икеайлык үткәрү эшләрен координацияләү өчен оператив штаб булдырырга һәм аның составын расларга (1 нче кушымта).

3.Район территориясен санитар чистарту планын расларга (2 нче кушымта).

4. Авыл җирлекләре башлыкларына:

икеайлык үткәрү турындагы мәгълүматны оешма һәм халык җитәкчеләренә җиткерергә;

ведомство буйсынуындагы территорияләрне санитар чистарту планнарын эшләргә;

икеайлык үткәрү эшләрен координацияләү өчен оператив штаблар булдырырга;

җирле үзидарә органнарының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затларының җирлекләр һәм шәһәр округлары территорияләрен төзекләндерү буенча муниципаль кагыйдәләрнең, калдыклар белән эш итүнең муниципаль кагыйдәләрнең үтәлешен тикшереп торуны көчәйтү өлешендә эшчәнлеген активлаштырырга;

су объектларының, пляжларның, скверларның, балалар мәйданчыкларының, азык-төлек һәм кием базарларының, халыкның күпләп ял

итү урыннарының, ял итү базаларын, бакчачылык җәмгыятьләрен һәм гараж кооперативларын, хосусый торак сектор территорияләрен, ташландык биналарны, иске корылмаларны һәм корылмаларны санитар чистарту чараларын уздырырга, алга таба автомобиль юлларының юл буе полосаларын, контейнер мәйданчыкларын төзү һәм ремонтлау, каты көнкүреш калдыклары өчен контейнерлар әзерләү һәм ремонтлау буенча чаралар үткәрергә;

каты көнкүреш һәм биологик калдыкларның (үләт базларының) полигоннарын тиешенчә карап тотуны һәм эксплуатацияләүне тәэмин итү һәм алар янындагы урыннарны санитар чистарту чараларын күрергә;

терлекчелек комплекслары калдыкларын рөхсәтсез урнаштыру урыннарын бетерү чараларын күрергә;

ведомство буйсынуындагы территорияләрне санитар-экологик чистарту эшенә ирекле нигездә иҗтимагый яшьләр (волонтерлык) оешмаларын җәлеп итәргә;

«Татарстан Республикасының экологик картасы» Геомәгълүмат системасы http://ecokarta.tatar.ru/, шул исәптән «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы, «Мәктәп экопатруле» мобиль кушымтасы ярдәмендә ишегалды территорияләрендә рөхсәтсез калдыклар урнаштыру урыннарын юкка чыгару мониторингын үткәрергә;

әлеге карарның 3 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча икеайлык үткәрүнең барышы турында мәгълүматны Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенә атна саен, әлеге карарның 4 нче кушымтасы нигезендә – 2020 елның 7 һәм 21 апрель, 6, 19 һәм 26 май көннәрендә бирергә тәкъдим итәргә.

5. «Кайбыч ТКХ» муниципаль унитар предприятиесенә каты көнкүреш калдыкларын полигоннарга чыгару һәм күмү буенча коммуналь техниканың нәтиҗәле эшен тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

6. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының административ комиссиясенә җирлекләр территорияләрен төзекләндерү буенча муниципаль кагыйдәләр үтәлешен контрольдә тотуны көчәйтү буенча эшне активлаштырырга.

7. «Кайбыч таннары» («Кайбицкие зори») газетасының баш мөхәрриренә газетаның ике айлык барышын яктыртуны тәкъдим итәргә.

8. Халык катнашында барлык милек формаларындагы оешмалар коллективлары катнашында район үзәген, торак пунктларны, күпләп ял итү зоналарын төзекләндерү һәм санитар чистарту буенча даими чаралар уздыру практикасын кертергә.

9. Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы Б.Р.Сәлаховка икеайлыкны үткәрү эшләре барышы турында әлеге карарның 3 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча һәр атнаның чәршәмбесендә, әлеге карарның 4 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча - 8, 22 апрель, 6, 20 һәм 27 май көннәрендә Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгына мәгълүмат бирергә.

10. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы

буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» бастырырга.

11. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең төзелеш һәм ТКХ буенча урынбасары Ф.Ш.Әхмәтовка йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 е. «23» 03. 156
номерлы карарына 1нче кушымта

**Икеайлык үткәрү эшләрен координацияләү өчен оператив штаб составы**

| | |
|---|---|
| Әхмәтов Ф.Ш. | Башкарма комитет Җитәкчесенең төзелеш һәм ТКХ буенча урынбасары |
| Камалетдинов Р.М. | Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Решеткина Н.И. | Татарстан Республикасының Зеленодольск, Югары Ослан, Кама Тамагы районнарында «Гигиена һәм эпидемиология үзәге» ФБССУнең Кайбыч филиалы мөдире (килешү буенча) |
| Хуҗин Р.Г. | Россия ЭЭМ Кайбыч районы бүлекчәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Зиядиев И.М. | Кайбыч РДВБ башлыгы (килешү буенча) |
| Сөнгатуллина Л.М. | «Кайбыч таннары» («Кайбицкие зори») газетасы баш мөхәррире (килешү буенча) |
| Хәмидуллин И.И. | «Башкарма комитетның Мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы |
| Зиннуров Ф.Р. | «Кайбыч ТКХ» МУП директоры (килешү буенча) |
| Ибраһимов Д.Р. | Россия ГХМ ТР буенча 115 нче ЯКЧ «8 отряд» башлыгы (килешү буенча) |
| Гыйльметдинов Ф.А. | «Кайбыч махсус орлыкчылык урман хуҗалыгы» ДБУ директоры (килешү буенча) |

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 е. «23» 03 156
номерлы карарына 2нче кушымта

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында санитар чистарту һәм санитар-экологик хәлне яхшырту буенча чаралар планы**

| т/б № | Чара атамасы | Үтәү вакыты | башкаручылар |
|---|---|---|---|
| 1 | Район предприятиеләренә һәм оешмаларына 2020 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр район торак пунктлары территорияләрен санитар чистарту икеайлыгы уздыру турында хәбәр итү. | 01.04.2020 кадәр | Авыл җирлекләре Башкарма комитетлары, оешмалар, предприятиеләр җитәкчеләре |
| 2 | Эшне координацияләү өчен оператив штаблар төзү. | 26.03.2020 кадәр | Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты |
| 3 | Район оешмалары һәм предприятиеләре мәйданчыкларын, ишегалларын һәм аларга якын территорияләрне санитар чистарту эшләрен башкару | 01.05.2020 кадәр | Район оешмалары һәм предприятиеләре, бинала һәм корылмалар милекчеләре, торак пунктларда яшәүчеләр |
| 4 | Биналар һәм торак йортларның фасадларын ремонтлау | 31.05.2020 кадәр | Район оешмалары һәм предприятиеләре, биналар һәм корылмалар милекчеләре, торак пунктларда яшәүчеләр |
| 5 | Балалар мәйданчыкларын чистарту һәм төзекләндерү | 31.05.2020 кадәр | Авыл җирлекләре Башкарма комитетлары |
| 6 | Карт агачларны кисү, коймаларны ремонтлау һәм буяу | апрель-май | Авыл җирлекләре Башкарма комитетлары, «Кайбыч ТКХ» МУП |
| 7 | «Кошларга йорт» конкурсы | апрель 2020 | Мәгариф учреждениеләре |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 8 | Обелисклар, һәйкәлләр һәм аларның территорияләрен төзекләндерү | 01.05.2020 кадәр | Авыл җирлекләре Башкарма комитетлары |
| 9 | «Кошлар көне» бәйрәме | 01.04.2020. | Мәгариф учреждениеләре |
| 10 | «ЭКОЛОГ и Я» конкурсы | Апрель 2020 | «ЭКО» МТЭҮ |
| 11 | Макулатура җыю буенча акция | Апрель-май 2020 | Мәгариф учреждениеләре |
| 12 | Клумбалар ясау, булганнарын төзәтү, чәчәкләр, куаклар, агачлар утырту | 01.06.2020 кадәр | Район оешмалары һәм предприятиеләре, авыл җирлекләре Башкарма комитетлары |
| 13 | Районның электр линияләре баганаларын, агачларны, куакларны агарту | 01.05.2020 кадәр | Район оешмалары һәм предприятиеләре, авыл җирлекләре Башкарма комитетлары |
| 14 | Рөхсәтсез чүплекләрне ачыклау һәм бетерү | апрель-май 2020 | авыл җирлекләре Башкарма комитетлары |
| 15 | Беркетелгән территорияләр нигезендә юл буе полосаларын һәм юл кырыйларын җыештыру | 01.05.2020 кадәр | Район оешмалары һәм предприятиеләре, авыл җирлекләре Башкарма комитетлары |
| 16 | Чишмәләрне төзекләндерү һәм карап тору | май-июнь 2020 | авыл җирлекләре Башкарма комитетлары |
| 17 | Зират коймаларын төзекләндерү, ремонтлау, территорияләрен чистарту | апрель-май 2020 | Башкарма комитетлары, «Кайбыч ТКХ» МУП |
| 18 | Әйләнә-тирәне саклау буенча занятиеләр | апрель-май 2020 | Мәгариф учреждениеләре |
| 19 | «Яшел патруль» балалар рәсем конкурсы | 2020е. 15 апреленә кадәр | Мәгариф учреждениеләре |
| 20 | Йомгак ясау | Атна саен | Авыл җирлекләре Башкарма комитетлары, оешмалар, предприятиеләр җитәкчеләре |

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 е. «23» 03 156
номерлы карарына 3 нче кушымта

2020 елның ____________________ торышы буенча күзәтчелек органы эше турында мәгълүмат

| т/б № | муниципаль берәмлек атамасы | Ачыклан-ган тәртип бозулар | | Ачыклан рөхсәтсез чүплекләр | | | Бетерелгән рөхсәтсез чүплекләр | | | Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе Кодексының (Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексының) _ст. буенча төзелгән беркетмәләр саны, данә | | | | Административ җаваплылыкка тартылган | | | | штрафлар салынган, мең сум | Түләтелгән штрафлар, мең сум |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | барлыгы | Алардан юкка чыгарылган | саны, данә | мәйданы, кв. метр | күләме, куб. метр | саны, данә | мәйданы, кв. метр | күләме, куб. метр | барлыгы | Юридик затлар | Вазыйфаи затлар | граждан-нар | барлыгы | Юридик затлар | Вазыйфаи затлар | граждан-нар | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

Ф.И.А.и, җитәкче имзасы ________________________________

Искәрмә: Хисап датасына үсә барган нәтиҗә белән мәгълүматны тәкъдим итәргә.

________________________________

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 е. «23» 03 156
номерлы карарына 4 нче кушымта

2020 елның «___» _______торышы буенча Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары Башкарма комитетларының санитар-экологик икеайлык үткәрү эшләре барышы турында мәгълүматы

| № п/п | муниципаль берәмлек атамасы | Чыгарылган каты көнкүреш калдыклары күләме, куб.метр | | Катнашкан махсус автотранспорт, берәмлек | Катнашкан халык, берәмлек | Утыртылган агачлар, данә | Утыртылган куаклар, данә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | барлыгы | Шул исәптән полигоннарга | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |

Ф.И.А.и, җитәкче имзасы ______________________________

Искәрмә: Хисап датасына үсә барган нәтиҗә белән мәгълүматны тәкъдим итәргә.